Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы
«Ульяновка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге
ГРАЖДАННАРЫ ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы Ульяновка авыл җирлеге
составына керүче Сосновка авылы торак пунктында

11 ноябрь 2019 ел № 2/4

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Ульяновка авыл җирлегенең Сосновка авылы торак пунктында гражданнар җыены КАРАР КЫЛДЫ:

1. 2020 елда Чирмешән муниципаль районы Ульяновка авыл җирлегенең Сосновка авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 500 сум күләмендә үзара салым кертергә көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларында хезмәт итүчеләрдән, 1 төркем инвалидлардан тыш.

Алынган чараларны җибәрергә:

- Ульяновка, Нагорный, Саминовка, Сосновка, Девичья Поляна торак пунктларында урам утларын монтажлауга, урнаштыруга, ремонтлауга, карап тотуга һәм хезмәт күрсәтүгә, урам утларының бишенче чыбыгын урнаштыруга, урам утларын куллану чыгымнарын түләүгә, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алуга;
- Ульяновка, Нагорный, Саминовка, Сосновка, Девичья Поляна торак пунктларында җәйге һәм кышкы чорда җирле әһәмияттәге юлларны төзекләндерү, карап тоту, хезмәт күрсәтү (юл кырыйларын чабу, юлларны грейдерлау, урамнарны кышкы чорда кардан чистарту, ягулык-майлау материаллары сатып алу, хезмәтләр өчен түләү), югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу чыгымнарына;
- Ульяновка, Нагорный һәм Саминовка торак пунктларында су челтәрләрен реконструкцияләүне проектлаштыруга, су башнялары территориясен, скважиналарны төзекләндерүгә, кулланылган электр энергиясе һәм хезмәтләр өчен чыгымнарны түләүгә;
- "Сирена" тавышлы сөйләшү җайланмасын сатып алуга, урнаштыруга, монтажлауга, карап тотуга һәм хезмәт күрсәтүгә, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алуга;

Халык җыенында рәислек итүче
Ульяновка авыл җирлеге башлыгы: С.З. Шәмсетдинов